РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.02.2020 № 27-п

Саба муниципаль районында административ
хокук бозулар турында беркетмәләр
төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар
исемлеген раслау хакында

“Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 25 декабрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы үзгәрешләре, шул исәптән административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының яңа өстәлгән балигъ булмаганнарга тәмәкесез никотинлы продукция сатуны, никотин китерүнең электрон системаларын тыюны, шулай ук балигъ булмаганнарны тәмәкесез никотинлы продукция куллануга җәлеп итүне тыюны бозган өчен җаваплылык билгели торган 2.16 статьясы нигезендә, “Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында” 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон һәм “Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында” 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген расларга.

2. Саба муниципаль районы Башлыгының “Саба муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында” 2018 елның 11 декабрендәге 185-п номерлы карарының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязовка йөкләргә.

Р.Н. Минниханов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башлыгының
_________________________
___номерлы карары белән

РАСЛАНГАН

**Саба муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге**

| ***Татарстан Республикасы Кодексының административ хокук бозулар турында статьялары*** | ***Вазыйфаи затлар исемлеге*** |
|---|---|
| **ТР Кодексының АХБ турында 2.1 статьясы**<br>Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органының, предприятие, учреждение, башка оешманың үз исеме турында белешмә биргәндә һәм элмә тактасында урнаштырылырга тиешле бүтән мәгълүматны күрсәткәндә хокук бозуларга карата). | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 2.4 статьясы**<br>Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 2.5 статьясы**<br>Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яки тагып йөрү | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 2.6 статьясы**<br>Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү<br>**ТР Кодексының АХБ турында 2.7 статьясы** | - Саба муниципаль районы Советының юридик бүлек башлыгы;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |

| | |
|---|---|
| Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларын куллану тәртибен бозу | |
| **ТР Кодексының АХБ турында 2.8 статьясы**<br>Этил спирты булган өйдә ясалган продукцияне сату һәм (яки) сату максатларында җитештерү | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 2.12 статьясы**<br>Гражданнарны социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ кешеләр буларак исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу<br>**ТР Кодексының АХБ турында 2.13. статьясы**<br>Гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ кешеләр буларак исәпкә алу һәм аларның исәбен алып бару тәртибен бозу | Саба муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 2.14 статьясы**<br>Татарстан Республикасы территориясендә тартмый торган тәмәке эшләнмәләрен күпләп һәм ваклап сатуны тыюны бозу | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 2.16 статьясы**<br>Балигъ булмаганнарга тәмәкесез никотинлы продукция сатуны, никотин китерүнең электрон системаларын тыюны, шулай ук балигъ булмаганнарны тәмәкесез никотинлы продукция куллануга җәлеп итүне тыюны бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 3.2 статьясы**<br>Урам сәүдәсен оештыру тәртибен бозу<br>**ТР Кодексының АХБ турында 3.5 статьясы**<br>Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 3.3 статьясы**<br>Җир асты коммуникацияләрен карап тоту кагыйдәләрен бозу<br>**ТР Кодексының АХБ турында 3.4 статьясы**<br>Урам, квартал эчендә яктырту системасын карап тоту кагыйдәләрен бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе урынбасары;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча |

| | |
|---|---|
| **ТР Кодексының АХБ турында 3.6 статьясы**<br>Авыл җирлекләре һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу<br>**ТР Кодексының АХБ турында 3.17 статьясы**<br>Транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртә торган мәйданчыкларда, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру | муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 3.7 статьясы**<br>Этләрне урамда йөртү тәртибен бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе урынбасары;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклауны һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 3.8 статьясы**<br>Төнлә тынлыкны һәм гражданнарның тынычлыгын бозу | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 3.10 статьясы**<br>Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен бозу | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 3.11 статьясы**<br>Балалар сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәмәү | - Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең җаваплы сәркатибе;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 3.14 статьясы**<br>Мәдәни-тамаша чараларында булган вакытта җәмәгать тәртибен бозу | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |

| | |
|---|---|
| **ТР Кодексының АХБ турында 3.15 статьясы**<br>Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 3.16 статьясы**<br>Түләүле муниципаль парковкада (машина кую урыннарында) транспорт чараларын урнаштырган өчен түләмәү | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 4.4 статьясы**<br>Муниципаль милектә булган торак булмаган фонд объекты белән эш итү һәм әлеге объектны куллану тәртибен бозу | - Саба муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының баш белгече;<br>-Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |
| **ТР Кодексының АХБ турында 5.1 статьясы**<br>Билетсыз йөрү<br>**ТР Кодексының АХБ турында 5.2 статьясы**<br>Багаж йөртү кагыйдәләрен бозу<br>**ТР Кодексының АХБ турында 5.6 статьясы**<br>Пассажирны йөртүдән баш тарту | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе урынбасары;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече. |